XX гасырның икенче яртысыннан башлап, тел белемендә антропоцентрик юнәлеш өстенлек итә. Фридрих Вильгельм фон Гумбольдт (1769–1859) фикерләреннән үк үсеш алган әлеге юнәлешнең нигезендә телгә ия шәхес, тел шәхесе *(языковая личность)* төшенчәсе ята. «Нинди генә предмет турында сүз барса да, аны һәрвакыт кеше белән, ягъни аның интеллектуаль һәм әхлакый организмы белән бәйләп була», – дип яза В. Гумбольд [1, б. 161]. Иң беренче чиратта, телгә ия шәхес ул – сөйләм эшчәнлегенә сәләтле булган тел йөртүче кеше *(носитель языка)*. Телгә ия шәхес дип, шулай ук телне аралашу чарасы буларак кулланган кешенең сөйләм үзенчәлекләре җыелмасы күздә тотыла, ягъни бу очракта ул – коммуникатив шәхес [2, б. 200]. Мондый шәхес ана теленә нигезләнгән, ана теле аша кабул иткән нигез милли-мәдәни кыйммәтләргә, әйләнә-тирә дөньяга карата буыннар аша тапшырылган һәм тотрыкланган карашлар системасына ия. Туган тел аша кеше әкренләп тирә-юньдәге дөнья белән таныша, конкрет предметлардан, элементар тәртип нормаларыннан алып, абстракт төшенчәләр һәм дөнья төзелешенең эчке һәм тышкы закончалыклары турында белемгә ия була. Белемнәр системасын ул төрле юллар белән саклый һәм, үз чиратында, киләчәк буыннарга тапшыра. Шундый юлларның берсе – дөнья турындагы белемнәрне әдәби әсәр, андагы образлар, тасвирлаулар, персонажлар сөйләме аша тапшыру, ягъни, язучы шәхесе, аның теле аша дөнья турында күзаллаулар системасын булдыру. В.В. Катермина фикеренчә, «Без

язучының тел шәхесе асыл үзенчәлекләрен ике билгеләмә белән белдерергә мөмкин дип саныйбыз: беренчедән, язучы-иҗатчының тел шәхесе индивидуальләштерелгән; икенчедән, ул вакуумда түгел, ә дөньяның милли картинасы кысаларында яши һәм индивидуаль үзенчәлекләрне гомуми концептуаль фонда гына тормышка ашыра ала» [3, б. 209]. Язучы, телгә ия шәхес буларак, әдәби текст белән эш итә һәм әдәби әсәр тукымасында үзен уратып алган яисә үзенең аңында барлыкка килгән дөнья сурәтен гәүдәләндерә. Бу дөньяда персонажлар, әдәби образлар, каһарманнар аерым урын били һәм бу очракта язучы тасвиры индивидуаль [4]. Татар әдәбиятында үзенчәлекле образлар барлыкка китерү аеруча XX гасыр башында активлаша, ул татар халкының гореф-гадәтләре белән дә бәйле [5, б. 178]. Авторның тел шәхесе – иҗатчының шәхесен тулы мәгънәдә күрсәтү төре, ул психик, социаль, этик һәм башка компонентларны үз эченә ала, әмма аның теле, текстларының дискурсы аша чагылдырыла [3, б. 212]. Нәкъ менә шуңа күрә персонаж сөйләмен тикшергәндә, без, иң беренче чиратта, мондый сөйләм авторның тел шәхесе аркылы гәүдәләнгәнен онытмаска тиешбез.

Бу яссылыкта хәзерге чорга кадәр иҗат ителгән әсәрләр аеруча кызыксыну уята, чөнки борынгы һәм урта гасырларда яшәгән язучыларның этика кагыйдәсе буенча, әсәрдә авторның шәхесе турында мәгълүмат бирелми яисә бик аз күләмдә бирелә. Еш кына без авторның исемен дә, кайсы урынчалыктан (илдән) чыкканын да белмибез. Бу чорларда автор үз әсәрендә эреп югала, һәм аның образын (шәхесен) «җыю» еш кына автор аеруча калку итеп күрсәткән персонажлар сөйләмен тикшерү аша башкарыла. Мәсәлән, XIII гасырда иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» әсәрен язган кешенең исеме бары тик поэма ахырында ике юлда гына искә алына:

*Буни дүзән – зәгиф бәндә, ады Ғәли...* [6, б. 292] (Моны төзегән кеше – зәгыйфь бәндә, исеме Гали...)

*Рәхмәт қыйлғыл, рәхим қыйл Қул Ғәлийә* [6, б. 294] (Рәхмәт әйт, яхшылык күрсәт Кол Галигә).

Шул рәвешле, без автор турында башка мәгълүмат таба алмыйбыз. Әсәрдә ул үзен «зәгыйфь бәндә (кол)» дип атый, әмма моның күчерелмә мәгънәдә әйтелгәнен, урта гасыр шәрык әдәбиятындагы язучылык этикасы буенча, үзен беркадәр түбәнсетеп, дәрәҗәсен киметеп күрсәтү белән бәйле икәнлеге аңлашыла. Шуңа карамастан, автор һәм персонажлар сөйләме аша шагыйрьнең белем дәрәҗәсен, дөнья турында күзаллаулар системасын яхшы аңларга мөмкин. Гомумән, әсәрдә ялгызлык исемнәренең кулланышы бик үзенчәлекле һәм автор тарафыннан аерым максатны күздә тотып эшләнелә [7, б. 224].

## Тикшерену материаллары һәм методлары

Югарыда әйтелгәннән чыгып, әлеге мәкаләдә XIII гасыр язма истәлеге булган «Кыйссаи Йосыф» әсәрендәге Зөләйха образын барлыкка китерүдә автор кулланган тел-стиль чараларын ачыклау, ягъни Зөләйханың сөйләм портретын ачыклау максаты куела. Мисаллар Фазыл Фәсиев тарафыннан 1983 елда эшләнгән текстка [6, б. 3–294] нигезләнеп төзелгән ярдәмче тексттан алынды (хезмәттә текстологик максатлар күздә тотылмады). Тикшерүнең төп методлары буларак, тарихи-чагыштырмалы, тасвирлама һәм концептуаль методлар, тарихи-лингвистик һәм тарихи-стилистик анализ төрләре кулланылды. Тарихи-чагыштырмалы һәм тасвирлама методлар ярдәмендә әсәрдә тасвирланган күренешләрне иске төрки һәм хәзерге татар теле нигезендә чагыштыру юлы белән гомуми үзенчәлекләрне ачыклау эше башкарылды. Персонаж сөйләмендә кулланылган концептларны ачыклауда концептуаль анализ методы, сөйләм үзенчәлекләрен һәм тасвирлау чараларын билгеләүдә тарихи-лингвистик һәм тарихи-стилистик анализ төрләре кулланылды.

## Фикер алышу

«Кыйссаи Йосыф» поэмасы татар әдәбиятында һәм тел белемендә шактый яхшы өйрәнелгән әсәрләрнең берсе булып тора, әмма персонажларның сөйләм портретын өйрәнү ягыннан бу әсәр тикшерелмәгән. Соңгы эшләрнең берсе буларак, поэмада кешенең эчке дөньясын тасвирлау үзенчәлекләрен ачыклауны максат итеп куйган хезмәтне – М.А. Гобәеваның «Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф» (1233) әсәрендә кеше эчке дөньясының тел портреты» дип аталган кандидатлык диссертациясен күрсәтергә мөмкин [9].

Билгеле булганча, поэмада дөньяның дини китапларында тасвирланган сюжет – Йосыф пәйгамбәр тарихы бәян ителә. Әлеге сюжет Коръән Кәримнең йөзунбер аятьтән торган уникенче – «Йосыф» сүрәсендә бирелә. Әсәрдәге төп каһарманнар – Йагкуб, Йосыф

һәм аның агалары, Зөләйха образлары авторның үзенчәлекле теле аша тасвирланалар. Бу тел – монгол яуларына кадәр Идел буенда кулланылган иске төрки әдәби телнең югары формасы [9, б. 18].

«Кыйссаи Йосыф» поэмасы – әдәби әсәр, димәк, әдәби әсәргә хас булган барлык таләпләргә дә җавап бирә: эстетик-эмоциональ яктан, ул укучының хисләренә тәэсир итә һәм интеллектуаль ләззәт бирә; кешегә әйләнә-тирә дөньяны, шул исәптән кешене һәм аның эчке күңел дөньясын танып белергә мөмкинлек ача; әдәби әсәр кешенең шәхесен формалаштыра, аның кыйммәтләр системасын төзи, аны уйларга һәм хис итәргә өйрәтә, акыллырак, игелеклерәк итә, рухи яктан баета. Бу функцияләрне тормышка ашыру автор, персонаж тасвиры һәм сөйләме аша тәэмин ителә. Зөләйха образы – моның ачык мисалы.

Зөләйха – патша кызы, мәликзадә, дине буенча мәҗүси; кызның атасы тарафыннан никадәр сөекле икәнен күрсәтү өчен, автор Зөләйханы Йосыф белән чагыштыра: *Нә кем Йагҗуб Йусыфый сәүәр иди, Йусыф аның уйлуқындан кәтмәз иди, һәм Зөләйха атасына шуйлә ирди, бәлки дагы артуғрак сәүәр имди.* [6, б. 128]. (Йагкуб Йосыфны ничек яратса, Йосыф аның итәгеннән ничек төшмәсә, Зөләйха да үз атасына шулай иде, бәлки, артыграк та яраткандыр әле). Зөләйханың кадерле, сөекле, иркә кыз икәнен автор сурәт ярдәмендә кат-кат әйтә: *Йастуқы атасының дизи ирмеш* [6, б. 128]. (Ята торган урыны – әтисенең тезе икән). Әсәрдә Зөләйханың яше күрсәтелмәсә дә, чагыштырулар ярдәмендә тасвирланган искиткеч чибәрлеге бу образның төп шарты булып тора: *Тулун ай тик балқыр иди аның йүзи, Уҗмах ичрә хур-ел-ғәйнә биңзәр имди* [6, б. 128]. (Тулган ай кебек балкый иде аның йөзе, Оҗмахтагы хур кызына охшый инде)

Димәк, Зөләйха – Африка Мәгрибендә (көнбатышында) [6, б. 128] иң бай патшаларның берсе Тәймус патшаның (хәзерге Тунис иле булырга мөмкин) искиткеч чибәр, иркә, сөекле кызы – атасының тезендә ятып йоклаганда, төшендә Йосыфны күрә һәм аңа гашыйк була, бу турыда атасына сөйли. Тәймус патша шунда ук бу кешенең кайда яшәгәнен белү өчен бөтен байлыгын бирергә риза икәнен әйтә, әмма өч ел дәвамында бу сер чишелми. Зөләйха авырый башлый, әтисе иң көчле табибларны чакырса да, терелми. Автор тасвирында каршы куе алымы ярдәмендә авыру Зөләйха үзсүзле булып гәүдәләнә: *Ғаклы кәтди, йатыб уйқу һич уйумаз, Тәғам хазир кәлтүрүлсә, һәргиз йимәз, Кемсә берлә ултуруб сөз сөзләмәз, Һич этибба боңа дәрман билмәз имди* [6, б. 130]. (Акылы китте, яткач, һич йокламый, Ризык китерсәләр, бер дә ашамый, Кешеләр белән утырып һич сөйләшми, Бернинди табиблар да моңа дәва белми инде).

Бары тик теләгенә ирешкәч – Йосыфның кем икәнен белгәч кенә, Зөләйха яңадан элекке хәленә кайта: *Баг-буғауын шишдерди, ғақыл улды, байағыдан тили дәхи фәсих улды, нуры артды, сөзи дәхи мәлих улды, вәликин Йусыфый көп үгәр имди.* [6, б. 132]. (Бау-богавын чиштерде, акыллы булды, Элеккедән дә теле ачык булды, Нуры артты, сүзе бигрәк татлы булды, әмма Йосыфны нык сөяр инде). Димәк, укучы автор тасвиры аша Зөләйха белән булган беренче эпизодларда ук аның иркәләнеп үскән, һәрвакыт үз теләгенә ирешергә теләгән һәм ирешкән, үзсүзле кыз икәнен аңлый.

Алга таба Зөләйха бик күп мал-байлык белән, килен буларак, Мисырга килә: *Сәүенди: Морадыма ирдем, дәйүр, ғәзиз Мисыр җәмалини көрәм, дәйүр* [6, б. 134] (Сөенде: Теләгәнемә ирештем, ди, Мисыр иясенең йөзен күрәм дия). Берничә урында кабатланып килгән “морад-хаҗәт” лексемалары әсәрдә концепт дәрәҗәсенә күтәрелә.

Мисырда үзе теләгән Йосыфның юк икәнен күреп, Зөләйха бик нык өзгәләнә: *Зөләйха әйдүр: “Ирақ қалды бәнүм илем, Аh, нидән ғәләт дүшди бәним халем, Аh, дәриғә, үкүш рәнҗүм, узақ йолым, Нәчә күнлүк михнәт заир олды имди!* [6, б. 136]. (Ерак калды минем илем, Аһ, нидән ялгыш булды минем хәлем, Аһ, кызганыч, рәнҗүем күп, озак юлым, Ничә көнлек михнәт юкка булды инде!) Зөләйханың үз теләгемә ирешәм дип килүен һәм ялгышуын автор контекстуаль антитеза (*морадыма ирдем – ғәләт дүшди*) ярдәмендә бик төгәл тасвирлый. Бигрәк тә Зөләйханың «*Байык белең: бу бәңа лаик дәгүл»* [6, б. 136] (Төгәл белегез: бу ир миңа лаек түгел) дип әйтүе үзен Мисыр патшасыннан да өстен куюы турында сөйли. Әмма башка чара юк, Зөләйха дая (тәрбиячесе) киңәше белән Мисырда яшәп кала. Бу эпизодта автор кызыклы гыйбарә куллана: *Зөләйха бу үгүти рәуа көрди, Мисырда дормаклықға бойун вирди* [6, б. 136] (Зөләйха бу үгетне яхшы дип тапты, Мисырда торырга риза булды). *Бойун вирди* гыйбарәсен хәзерге татар теленә *риза булды* дип күчерсәк тә, нигездә, монда башка сурәт күзаллана: поэма телендә кулланылган *разый олды* һәм *бойун*

*вирди* гыйбарәләре мәгънә ягыннан бер үк түгел: *разый олды – ризалашты* (согласиться) һәм *бойун вирди – буйсынды* (подчиниться). Үзсүзле кызның буйсынуы аның холкында үзгәреш башланганы турында сөйли, әмма бу үзгәреш әле тотрыклы түгел.

Ниһаять, җиде елдан соң гына Зөләйха Мисырда кол итеп сатылган Йосыфны үз күзләре белән күрә һәм Мисыр патшасын аны сатып алырга күндерә: *Зөләйха әйдүр: "Қуйыңыз, бән дүшәйен, Тәлим йылғы хәсрәтимә кауышайын, Фирақ халин-әхуалин сурашайын, Хәқыйқәт, висаль күни дуғды имди"*. [6, б. 138] (Зөләйха әйтә: Җибәрегез, мин төшим, Күп елгы хәсрәтемә кавышыйм, Аерылу хәлен-әхвәлен сорыйм, Чыннан да, кавышу көне туды инде) *Олдур бәнүм хаҗәтим, бәллү билиң, Сизләр аны бәнүм үчүн сатун алың, Җүмлә малум аның үчүн фида әйләң, Нәчә бәһа диләрсә, вириң имди!* [6, б. 138] (Улдыр минем теләгәнем, төгәл белегез, Сез аны минем өчен сатып алыгыз, Барлык малны аның өчен фида кылыгыз, Күпме бәя теләсә дә, бирегез инде!). Әлеге өзектә *олдур бәнүм хаҗәтим* (ул – минем хаҗәтем, теләгәнем) һәм *сизләр аны бәнүм үчүн сатун алың* (сез аны минем өчен сатып алыгыз) гыйбарәләре безнең игътибарны җәлеп итә. Пәйгамбәр улы һәм үзе дә пәйгамбәр булган Йосыфны Зөләйха "теләгәнем, кирәгем" дип атый, ягъни аны "кеше" биеклегеннән "әйбер, уенчык" түбәнлегенә төшерә, "*минем өчен* сатып алыгыз" дип әйтә. Бу юлларда Зөләйха образы автор тасвиры нигезендә шулай ук үзсүзле, максатына ирешергә ратучан итеп тасвирлана.

Мисыр патшасы Йосыфны сатып алып, Зөләйхага «Улыбыз булсын» дип тапшыра: *Бәнән аңа артуғырак тәғзим қылғыл, бизим бу оғлумыз олсун имди* [6, б. 146] (Миннән дә артыграк аңа хөрмәт күрсәт, Безнең бу улыбыз булсын инде). Шул вакыттан алып, Зөләйханың хәле бик кыенлаша: автор гашыйк кызның халәтен бик төгәл тасвирлый: *Мөшкил хальгә дүшди ол анда кәзин, Бер сагәтгә көрмәсә Йусыф йүзин, Сабыры қалмаз, аңламаз кимсә сөзин, Нә сөзләсә, "Йусыф!" дәйү сөзләр имди.* [6, б. 148] (Мөшкел хәлгә төште ул анда соңрак, Бер сәгатькә күрмәсә Йосыф йөзен, Сабыры калмас, аңламас кеше сүзен, Ни сөйләсә дә, Йосыф дип сөйли инде); *Бәрдазан тәниндән қан алдырса, Хәҗҗәм аның тамырына ништәр урса, Ғәлялхаль қаны ақыб, йирә тамса, Йир үзрә Йусыф ады йазылур имди!* [6, б. 148]. (Бераздан тәненнән кан алдырса, Кан алучы аның тамырына пычак тидерсә, Хәләл каны агып, җиргә тамса, Җир өстенә Йосыф исеме языла инде!); *Һәр заманда көкләр таба нәзар қылса, Күк йөзиндә улдызлары көрәр исә, Һәмандәм Йусыф анда кәлүр исә, Улдызлар [һәм] Йусыф дәйү сөзләр имди!* [6, б. 148]. (Һәр заманда күк йөзенә күз салса, Күк йөзендә йолдызларны күрсә, Шул вакытта Йосыф анда килсә, Йолдызлар да Йосыф диеп сөйли инде!) Әлеге юлларны биредә тулаем китерүнең максаты – авторның сүз байлыгын һәм тасвир көчен күрсәтү: күрәсең, автор Зөләйханың киләчәктәге дин һәм әхлак ягыннан дөрес булмаган гамәлләрен беркадәр аклау өчен, аларның сәбәбен бик көчле гашыйк булуга кайтарып калдырырга омтыла. Чыннан да, Зөләйха Йосыф белән потханәгә керә һәм потка ялвара: *Йалуарыр ол санәмгә, зари әйләр, зирә-ки ғыйшқы ғалиб, сабыры аулар, Хатириндә қалмади [һич] гизлү әсрар, нә чар олуб, бутынә йалуарыр имди.* [6, б. 148]. (Ялвара ул потка, елый-елый, Бигрәк инде гыйшкы зур, сабыры калмый, Күңелендә калмады яшерен серләр, Чарасыз булып, потка ялвара инде). Әлеге эпизод, бердән, Йосыфның пәйгамбәрлек көчен күрсәтү өчен китерелсә (Йосыф потны тар-мар итә, җимерә һәм, Зөләйха үтенече буенча, яңадан элекке хәленә кайтара); икенчедән, Зөләйханың үз максатына ирешү өчен төрле юлларны кулланып каравы, ягъни, кызу канлы булуы, уйламыйча эш итүе һәм эмоциональ яктан бик хисле булуы турында сөйли. Зөләйха моның белән генә тынычланмый: аңа, бернигә карамый, үз максатына ирешергә – Йосыфны үзенеке итәргә, аның белән ислам динендә тыелган никахсыз җенси мөнәсәбәткә керергә кирәк. Бу максат, бу теләк аңа грандиоз эш алып барырга – дая өйрәтүе буенча, дөньяда тиңе булмаган бик зур сарай салдырырга, аны кыйммәтле ташлар, сыннар, рәсемнәр белән бизәргә, анда Йосыфны алып кереп, үзенә кызыктырырга һәм шул рәвешле үз максатына ирешергә этәрә. Автор тәхеттә утырган, киенгән-ясанган, искиткеч гүзәл Зөләйханы сурәтләү чаралары ярдәмендә болай тасвирлый: *Тадҗ кийәр, қаш ойнатур, көзин сүзәр, Сөзләдүкчә нәфәсендән ғәнбәр тозар, Һәман фирдәүес эчрә хурларә биңзәр, Айағындан мәрҗан хали қушар имди* [6, б. 158]. (Таҗ кия, каш уйната, күзен кыса, Сөйләгәндә сулышыннан хуш ис килә, Җәннәт эчендәге хур кызына охшый, Аягында мәрҗаннан ясалган бөҗра инде). Биредә дә Йосыфка эндәшкәндә,

ул үзенең максаты, теләге турында сөйли: *Хатун әйдүр: «Бән сәни дүшдә күрдүм, Андан бирү җәмалеңә гашиқ олдум, Малум-мөлкүм җүмләсин фида қылдым, Морадым бу күн хасил қыйлам имди».* [6, б. 158] (Хатын әйтә: Мин сине төштә күрдем, Шуннан бирле йөзеңә гашыйк булдым, Малым-мөлкәтемнең барысын фида кылдым, Теләгемне бүген тормышка ашырам инде). Шул рәвешле, автор Зөләйханың хәләл булмаган мәхәббәт тарихын <u>морад</u> (максат, теләк, омтылыш) концептына җыеп кертә.

Зөләйханың үз максатына ирешү юлында төп коралы – сүз. Һәм ул сөйли. Йосыфның кисәтүләренә карамастан, аны тыңламыйча, бары үз сүзен, үзенең кичерешләре турында кат-кат сөйли. Бу юлларда шулай ук Зөләйханың сөйләм портреты аша холкы ачыла: *Зөләйха ол сөзләри һич аңламаз, Йусыф пәнден дыңламаз, рәуа күрмәз, аңа лаиқ кәлачи сөз сөзләмәз, Кәнде сөзин мөкәррәр сүйләр имди.* [6, б. 160] (Зөләйха ул сүзләрне һич аңламый, Йосыф киңәшен тыңламый, яхшы дип уйламый, Аңа лаек әйтелгән сүз сөйләми, Үз сүзен кат-кат сөйли инде). Бер яктан, гашыйк кешенең эмоциональ халәте зур осталык белән тасвирланса, икенче яктан, образны тулыландыра торган өстәмә детальләр – мәдхия жанрын хәтерләткән сөйләм тасвиры килеп керә: *Әйдүр: «Әйа Йусыф, сәниң сөзиң датлу, усанмадан дыңламаға нә рахәтлү, Йүзиң лятиф, кәлачиң хуб, мөрәүүәтлү, Ишитсәм, рахәтүм артар имди».* [6, б. 160]. (Әйтә: Әй, Йосыф, синең сүзең татлы, Эч пошканда тыңларга ни рәхәт, Йөзең матур, сүзең яхшы, нурлы, Ишетсәм, рәхәтем арта инде); *Висалең – диларәм, җан рахәти, Җәмалең қуйаш кеби, ғишқың қаты, Сурәтиң ғәҗәб төрфә, ләфзың йети, Хәнҗәр кеби, җанымдан кәчәр имди.* [6, б. 160] (Синең белән күрешү – татлы, җан рәхәте, Йөзең кояш кебек, гыйшкың каты, Сурәтең гаҗәп матур, сүзең үткен, Хәнҗәр кебек, җанымнан кичә инде); *Һиляля биңзәр сәниң қашларың вар, Йенҗүйә биңзәр сәниң дишләриң вар, Ғәҗәб зиба мишик-йопар сачләриң вар, Кәнди әлүм үрмәгә лаиқ имди.* [6, б. 162] (Айга охшаган синең кашларың бар, Энҗегә охшаган синең тешләрең бар, Гаҗәп зифа, хуш ис килгән чәчләрең бар, Үз кулым белән үрергә лаек инде); *Ғәҗәб төрфә, қара рәңлү зөлфләриң вар, Хәлауәтлү, мөрәүүәтлү сөзләриң вар, Ғәмзә қылса, дилдин кәчәр көзләрең вар, Керпекләриң җанымдан кәчәр имди.* [6. б. 162] (Гаҗәп йомшак, кара төстәге толымнарың бар, Җанга якын, нурлы сүзләрең бар, Бер караса, сүзсез калырдай күзләрең бар, Керфекләрең җанымнан үтә инде). Әлеге өзектә китерелгән мисаллар Зөләйханың тел байлыгын, аның сөйләм оештыру сәләтен, мантыйк дәрәҗәсен күрсәтә. Бу юлларда Зөләйха (автор каләме ярдәмендә) сүз белән сурәт барлыкка китерә, автор Зөләйха күзләре аша Йосыфның тышкы кыяфәтен – портретын торгыза. Әлеге юллар шул вакыттагы төрки әдәби телнең сурәтләү чаралары – металогик һәм автологик алымнар кулланып ясалган югары формасын тәшкил итә һәм «Кыйссаи Йосыф» әсәренең тел, сөйләм ягыннан иң гүзәл сәхифәләренең берсе булып тора.

Зөләйха, сөйләмнең барлык мөмкинлекләрен кулланып та, максатына ирешмәгәч, иң көчле психологик алымга бара – Йосыфның мин-минлегенә кагыла: *Зөләйха әйдүр: «Имди сән нә санырсән, Көңүлүңдә нә кәчәр, нә уманурсән, Әйт бәңа сән, кимсәдин коркурмусән, Йигитликдә һич насибың йуқму имди?»* [6, б. 164]. (Зөләйха әйтә: Инде син ни уйлыйсың, Күңелеңнән ниләр кичә, ни өмет итәсең, Әйт миңа син, кемнәндер куркасыңмы, Егетлегең юкмы әллә инде?) Бу юлларда нәкъ безгә таныш Зөләйха – үз максатына теләсә нинди юл белән ирешергә күнеккән иркә кыз гәүдәләнә, ул хәтта сөйгән кешесен рәнҗетүдән дә курыкмый. Шушы психологик алым белән дә теләгенә ирешә алмагач һәм ире алдында оятлы булып калгач, Зөләйха ярсый, гаделсезлек, явызлык күрсәтә, Йосыфны зинданга яптырырга тели: *Зөләйха әйдүр: «Бу угланны зинданлағыл, тәһдид қыйлғыл, қурқытғыл, өгүтләгил, гәр йуқсә, бәни қойуб, аны бәкләгил, әдәбсизлик қыйлмасун! – дәйүр имди».* [6, б. 170]. (Зөләйха әйтә: Бу баланы зинданга сал, өркет үзен, куркыт һәм үгетлә, Оят булыр, мине куеп, аны якласаң, Әдәпсезлек кылмасын! – дия инде). Зөләйха Йосыфка соңгы тапкыр ультиматум куя – я ул Зөләйханың теләген үтәп, сөяркәсе була, яисә зинданга ябыла [6, б. 178]. Йосыф зинданны кулайрак күргәч, Зөләйха бик каты ярсый һәм аның ачуын автор сүз аша җиткерә: *Аны ишдеб, Зөләйха йаулақ бушды, Ғәри кәлди, хатеринә хәйлә дүшди, Йусыфың билиндән қәмәр шишди, хәрир-зиба тунларин суйар имди* [6, б. 178] (Аны ишетеп, Зөләйха бик нык ачуланды, Ояты килде, хәтеренә хәйлә төште, Йосыфның биленнән кылычын чиште, ефәк-зифа киемнәрен салдыра инде). Әлеге юлларда без үз

теләгенә ирешә алмаган хатын-кызның дуамал холкын таныйбыз.

Шактый озак вакыт үтә. Ире Кыйтфирнең үлеменнән соң урамга куылган, зәгыйфь, күзе күрмәгән һәм карчыкка әйләнгән Зөләйха барыбер Йосыфны онытмый. Һәм холкына туры калып, бу михнәтләрдә ул үзен түгел, ә кыен вакытларда үзенә ярдәм итмәгән потларны гаепли: *Ғәзиз ирдүм – тул, ғәриб, ғәҗиз қалдым, Йусыф ғишқы күйдүрди, зәлил олдум, Әхуалүм бу күнгәчә заһир қылдым, Сәндән мәдәд йуқ имиш, билдим имди.* [6, б. 212] (Сөекле идем – тол, гарип, гаҗиз калдым, Йосыф гыйшкы көйдерде, түбәнлеккә төштем, Хәлемне бу көнгәчә сөйләп килдем, Синнән ярдәм юк икән, белдем инде); *Мисыр эчрә улу хатун олур идүм, Адәмләргә сәрвәрликни қылур ирдүм, андан бирү сәни мәғбуд билүр ирдүм, һич сәбәбдән рахәтең дигмәз имди!..* [6, б. 212] (Мисырда олы хатын идем, кешеләргә җитәкчелек кыла идем, Аннан бигрәк сине тәңре дип белә идем, Һич сәбәптән рәхәтең (ярдәмең) тими инде!) Әлеге строфаларда автор каршы куюга нигезләнгән сурәтләү алымы – антитеза куллана. Гомумән, антитеза – Кол Галинең иң яраткан сурәтләү чарасы һәм ул әсәрнең сюжетына бик туры килгән алым, чөнки төп каһарманнарның тормышы күтәрелү һәм төшүләрдән, капма-каршылыклардан тора. Антитеза алымы бигрәк тә Йосыф һәм Зөләйха образларын тасвирлаганда, киң кулланыла.

Үзе табынган потлардан ярдәм көтеп җиткерә алмагач, Зөләйха, мәҗүсилектән баш тартып, ислам динен кабул итә. Йосыф белән очрашкан вакытта аның сөйләме дә инде башка тонда, башкача төзелә: *Бән улмән, сәни сатун алдым иди, җүмлә малум сәңа фида қылдым иди, сәниң дәрдиң билә хәйран қалдым иди, бу күн имди бу халә дүшдүм имди.* [6, б. 214] (Мин – ул кеше, сине сатып алган идем, Барлык малымны сиңа фида кылган идем, Синең дәртең белән хәйран калган идем, Бүген инде бу хәлгә төштем инде); *Барчә кәтди әлимдән үкүш ниғмәт, бирси қалмай суалды мал вә мөлкәт, вәлякин һич суалмаз ғишқу хәсрәт, ғәля-д-дәуам ғишық оды үртәр имди.* [6, б. 214] (Барысы китте кулымнан – бик күп нигъмәт, берсе калмый югалды мал һәм мөлкәт, әмма һич югалмый гыйшык хәсрәте, Һәрдаим гыйшык уты өтә инде).

Әлеге юлларда без Зөләйханың сөйләме нигезендә аның холкы да үзгәрүен күрәбез: кызның мин-минлеге, дуамаллыгы югалган, ул үзенең халәтен бик яхшы аңлый, шуңа күрә язмышына да карышмый. Әмма бу эпизодта да аның үз-үзен бик ярата торган хатын-кыз булуы чагыла: Йосыф белән кавышачагын белгәч, ул каушап кала, иң элек Аллаһтан үзенең матурлыгын кире кайтаруны сорый: *Бәс, мәүлүмдән әмер-хөкем уйлә олса, көзләрүмнүң нуры кайра йәнә кәлсә, җәмалүм һәм Йусуфа лаиқ олса, мәүлүмдән ғинайәт умармын имди* [6, б. 216]. (Ходамнан әмер-хөкем булсын иде, күзләремнең нуры кабат миңа кайтсын иде, кыяфәтем Йосыфка лаек булсын иде, Ходамнан мин ярдәм өмет итәм инде). Мисырга килгән вакытта Зөләйха үзенә лаек кешене эзләсә [6, б. 136], бу юлларда без Зөләйханың Йосыфка лаек булырга теләвен күрәбез. Шул ук вакытта авторга Зөләйханың Мисыр патшасы хатыны булып та, пәйгамбәр Йосыф белән никахлашканда, саф кыз булып калуы әһәмиятле: патша янына Зөләйха кыяфәтендәге пәри кызы килеп йөрүе ачыклана [6, б. 218].

Зөләйха образы поэмада Йосыфның атасы Йагкуб пәйгамбәр белән очрашу эпизодына кадәр тасвирлана, әсәрнең соңында без аның вафаты [6, б. 288] һәм Йосыфның башка хатын-кызга өйләнмәве турында беләбез.

## Төп нәтиҗәләр

Шул рәвешле, Зөләйханың Кол Гали тарафыннан барлыкка китерелгән сөйләм портреты төрле ситуацияләргә бәйле булган тасвирый сыйфатламаларга, чагыштыруларга, канатлы гыйбарәләргә, антитезага, риторик сорауларга һ.б. сурәтләү чараларына корыла. Зөләйха сөйләменең мондый дискурсив, эмоциональ сыйфаты персонаж холкының каршылыклы булуы һәм аның поэма дәвамында үзгәрүе белән аңлатыла: Зөләйха тасвирының башлам өлешендә иркә, үзсүзле, үзенең теләгенә теләсә нинди юл белән ирешергә күнеккән мәҗүси патша кызы әсәр ахырында пәйгамбәр хатынына лаек булган сыйфатларны ала һәм Йосыф пәйгамбәр белән никахлашып, унике ир бала тудырган, аларны ислам дине һәм шәригать кануннары нигезендә тәрбияләгән зирәк акыллы Ана образы буларак гәүдәләнә.

**Әдәбият**

1. *Гумбольд В.* Язык и философия культуры. М: Прогресс, 1985. 450 с.
2. *Костомаров П. И.* Антропоцентризм как важнейший признак современной лингвистики // Вестник Кемеровского государственного университета. 2014. № 2 (58). Т. 1. С. 198–203.

3. *Катермина В. В.* Языковая личность автора в художественном тексте В.В. Катермина // Человек. Культура. Образование. 2016. № 2 (20). С. 205–213.

4. *Kamalieva A. M.* Ayaz Ishakî piyeslerinde milliyetçilik / Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: материалы международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки / сост.: Ф. Х. Миннуллина, А. Ф. Ганиева, Л. Р. Надыршина. Казань: ИЯЛИ, 2018. 450 с.

5. *Kamalieva A. M.* Mirhaydar Feyzi'nin "Galiyabanu" Dramında Tatar Gelenek ve Görenekleri / Türk Dünyası İncelemeleri Dergisi. Volume 18, Issue 1, 2018. P. 179–194.

6. Кол Гали. Кыйссаи Йосыф / Төп текстны (транскрипцияне) әзерләүче, кереш мәкаләне, искәрмә һәм аңлатмаларны, кулъязмаларның тасвирламасын ясаучы филология фәннәре кандидаты Ф. С. Фәсиев. Казан: тат.кит.нәшр., 1983. 542 б.

7. *Kuzmina K., Galiullina G. R., Kajumova Z. M., Kamalieva A. M.* Allusive proper names in the 13th century poem «Kissa-i yusuf» by Kul Gali [Nombres propios alusivos en el poema del siglo XIII Kissa-i Yusuf por Kul Gali]. – Utopia y Praxis Latinoamericana. Volume: 25. Issu: Extra 7. 2020. P. 224–230.

8. *Кузьмина Х.* Лексическая репрезентация понятия «пророк» в поэме Кул-Гали «Кысса-и Йусуф» // Tatarica. 2020. № 14. С. 18–27.

9. *Губаева М. А.* Языковой портрет внутреннего мира человека в произведении Кул Гали «Кысса-и Йусуф» (1233): дис ... канд. филол. наук: 10.02.02 // ФГАОУВО «Казанский (Приволжский) федеральный университет», 2017. 284 с.

# РЕЧЕВОЙ ПОРТРЕТ ЗУЛЕЙХИ В ПОЭМЕ «КЫССА-И ЙУСУФ» КУЛ ГАЛИ (XIII В.)

**Халиса Хатиповна Кузьмина**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
shirmanx@yandex.ru.

**Алсу Миннеахметовна Камалиева**,
Бартынский университет,
Турция, Бартын,74100, Кампус Кутлубей Языджылар,
akema@mail.ru.

Произведение Кул Гали «Кысса-и Йусуф» – поэма, написанная в XIII веке на тюркском литературном языке, на протяжении долгих веков любимая татарским народом, многократно переписанная от руки и впервые напечатанная в XIX веке. В регионах, где проживают татары, найдено более 300 рукописных копий этого произведения. Сюжетная линия поэмы восходит к истории прекрасного Иосифа, встречающейся в священных книгах большинства ортодоксальных религий, но значительно отличается деталями и описанием героев. Один из таких героев – Зулейха. В данной статье рассматриваются художественные средства выразительности, выбранные автором для создания образа Зулейхи, ее речевого портрета и для раскрытия особенностей ее характера.

**Ключевые слова:** речевой портрет, история татарского языка, Кул Гали, «Кысса-и Йусуф», «Сказание о Юсуфе», Зулейха, языковой портрет